ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 102 от «28» 03 2019 г.

Шәһәр һәм район территорияләрен чистарту
буенча санитар- экологик икеайлык
игълан итү турында

Санитар-эпидемиологик һәм экологик хәлне яхшырту, кеше саулыгына әйләнә-тирә мохитнең зарарлы һәм куркыныч факторлары йогынтысы дәрәҗәсен киметү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 21 мартында кабул ителгән б-567 нче санлы боерыгын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. 2019 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр шәһәр һәм район торак пунктлары территорияләрен чистарту буенча санитария-экология икеайлыгын игълан итәргә.

2. Мамадыш муниципаль районы авыл җирлекләре һәм Мамадыш шәһәре башкарма комитеты җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- ведомство карамагындагы территорияләрнең санитар-экологик хәлен яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар планын эшләргә һәм 2019 елның 29 мартына кадәр раслауны;

- икеайлык үткәрү эшләрен координацияләү өчен оператив штаблар төзергә;

- авыл җирлекләре һәм Мамадыш шәһәре территорияләрен төзекләндерүнең муниципаль кагыйдәләре, калдыклар белән эш итүнең муниципаль кагыйдәләре үтәлешен тикшерүдә тотуны көчәйтү өлешендә җирле үзидарә органнарының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары эшен активлаштыруны;

- су объектларының су саклау зоналарын, пляжларны, скверларны, паркларны, балалар мәйданчыкларын, азык-төлек һәм әйбер базарларын, халык күпләп ял итә торган урыннарны, зиратларны, шәхси торак сектор территорияләрен, ташландык биналар, тузган төзелешләрне һәм корылмаларны санитар чистарту, аларны дератизацион эшкәртү, автомобиль юлларының юл буе полосалары, контейнер мәйданчыкларын төзү һәм ремонтлау буенча чаралар үткәрергә;

- каты көнкүреш һәм биологик калдыклар (үләт базлары) полигоннарын тиешенчә карап тотуны һәм эксплуатацияләүне тәэмин итү һәм алар янындагы урыннарны санитар чистарту буенча чаралар күрүне;

- терлекчелек комплекслары калдыкларын рөхсәтсез урнаштыру урыннарын бетерү буенча чаралар күрүне;

- «Татарстан Республикасы Экологик картасы» геомәгълүмат системасы http://ecokarta.tatar.ru/ ярдәмендә ведомство буйсынуындагы территориядә

калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннарын бетерү мониторингын гамәлгә ашыруны, шул исәптән «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы, «Мәктәп экопатруле» мобиль кушымтасы чаралары буенча кергән хәбәрләрне дә исәпкә алып;

- Мамадыш муниципаль районының административ комиссиясенә һәм Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлегенә шәһәр һәм район территорияләрен язгы санитар чистарту һәм төзекләндерү эшләрен координацияләүне тәкъдим итәргә, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 21 мартында кабул ителгән б-567 нче санлы боерыгына теркәлеп килүче кушымталар нигезендә: 1 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча икеайлык үткәрү эшләре барышы турындагы мәгълүматны атна саен, чәршәмбе, 2 нче санлы форма буенча 2019 елның 10, 24 апрелендә, 8, 22 һәм 29 маенда (аңлатма язуын теркәп) Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгына җибәрүне.

3.ҖЧҖ “Эколидер” оешмасына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Каты көнкүреш калдыкларын кабул итү, сортларга аеру һәм күмү буенча эш алып барырга, чүп чыгару өчен махсус машина паркы һәм чүп полигоннарының нәтиҗәле эшен тәэмин итәргә;

4. Мамадыш муниципаль районының административ комиссиясенә һәм Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлегенә “ Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы Мамадыш районы һәм Мамадыш шәһәре буенча территориаль идарәсенә (Маснавиева М.Х.), ; Мамадыш шәһәре һәм районның авыл җирлекләре территориясендә сәнәгать һәм көнкүреш калдыклары белән эш итүне җайга салу өлкәсендә контрольне көчәйтергә тәкъдим итәргә.

5. Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (С.Н.Ханова) икеайлык кысаларында үткәрелә торган эшне “Нократ” (“Вятка”) газетасында әледән-әле яктыртып торуны тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов